КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 28 май г.Казань № 435

Торак-коммуналь хуҗалыкны реформалаштыруга булышлык күрсәтү фондыннан – дәүләт корпорациясеннән кергән акча исәбеннән коммуналь инфраструктура системаларын модернизацияләү чараларын үткәрү чыгымнарының бер өлешен түләү буенча муниципаль берәмлекләрнең чыгым йөкләмәләре үтәлешен финанслар белән тәэмин итү өчен Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләре бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибен раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән Торак-коммуналь хуҗалыкны реформалаштыруга булышлык күрсәтү фондыннан – дәүләт корпорациясеннән кергән акча исәбеннән коммуналь инфраструктура системаларын модернизацияләү чараларын үткәрү чыгымнарының бер өлешен түләү буенча муниципаль берәмлекләрнең чыгым йөкләмәләре үтәлешен финанслар белән тәэмин итү өчен Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләре бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибен расларга.

2. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2020 ел, 28 май, 435 нче
карары белән расланды

Торак-коммуналь хуҗалыкны реформалаштыруга булышлык күрсәтү фондыннан – дәүләт корпорациясеннән кергән акча исәбеннән коммуналь инфраструктура системаларын модернизацияләү чараларын үткәрү чыгымнарының бер өлешен түләү буенча муниципаль берәмлекләрнең чыгым йөкләмәләре үтәлешен финанслар белән тәэмин итү өчен Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләре бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар бирү
тәртибе

1. Бу Тәртип Торак-коммуналь хуҗалыкны реформалаштыруга булышлык күрсәтү фондыннан – дәүләт корпорациясеннән кергән акча исәбеннән коммуналь инфраструктура системаларын модернизацияләү чараларын үткәрү чыгымнарының бер өлешен түләү буенча муниципаль берәмлекләрнең чыгым йөкләмәләре үтәлешен финанслар белән тәэмин итү өчен Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләре бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар (алга таба – башка бюджетара трансфертлар) бирү механизмын билгели.

2. Башка бюджетара трансфертлар Торак-коммуналь хуҗалыкны реформалаштыруга булышлык күрсәтү фондыннан – дәүләт корпорациясеннән кергән акча исәбеннән коммуналь инфраструктура системаларын модернизацияләү чараларын үткәрү чыгымнарының бер өлешен түләү буенча муниципаль берәмлекләрнең чыгым йөкләмәләре үтәлешен финанслар белән тәэмин итү максатларында Татарстан Республикасының муниципаль районнары (алга таба – муниципаль берәмлекләр) бюджетларына бирелә.

3. Бу Тәртип нигезендә бирелә торган бюджет акчасы белән баш эш итүче булып Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы (алга таба – Министрлык) тора.

4. Башка бюджетара трансфертлар бу Тәртипнең 2 нче пунктында күрсәтелгән максатлар өчен тиешле финанс елына Министрлыкка җиткерелгән бюджет ассигнованиеләре һәм бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә бирелә.

5. Башка бюджетара трансфертлар түбәндәге критерийларга җавап бирә торган муниципаль берәмлекләр бюджетларына бирелә:

Торак-коммуналь хуҗалыкны реформалаштыруга булышлык күрсәтү фонды – дәүләт корпорациясе идарәсенең муниципаль берәмлектә коммуналь инфраструктура системасын модернизацияләү проектын тормышка ашыру өчен финанс ярдәме күрсәтү турында кабул ителгән карары булу;

коммуналь инфраструктура системасын модернизацияләү проектын тормышка ашыру өчен Торак-коммуналь хуҗалыкны реформалаштыруга булышлык күрсәтү фонды – дәүләт корпорациясе акчасы исәбеннән финанс ярдәме күрсәтү турында төзелгән шартнамә булу.

6. Һәр муниципаль берәмлек өчен башка бюджетара трансфертлар күләме Торак-коммуналь хуҗалыкны реформалаштыруга булышлык күрсәтү фонды – дәүләт корпорациясе идарәсенең муниципаль берәмлектә коммуналь инфраструктура системасын модернизацияләү проектын тормышка ашыруга финанс ярдәме күрсәтү турындагы карары белән билгеләнә.

7. Башка бюджетара трансфертлар бирү шартлары түбәндәгеләр була:

муниципаль берәмлекнең тормышка ашыру максатларында башка бюджетара трансфертлар бирү гамәлгә ашырыла торган чаралар исемлеген раслый торган хокукый акты булу;

муниципаль берәмлек һәм инвестор арасында имзаланган һәм Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтендә теркәлгән, Торак-коммуналь хуҗалыкны реформалаштыруга булышлык күрсәтү фонды – дәүләт корпорациясе идарәсенең муниципаль берәмлектә коммуналь инфраструктура системасын модернизацияләү проектын тормышка ашыруга финанс ярдәме күрсәтү турындагы карары белән хупланган коммуналь инфраструктура объектларына карата концессия килешүе булу;

муниципаль берәмлек бюджетында Татарстан Республикасы бюджетыннан бирергә планлаштырыла торган башка бюджетара трансфертларны үз эченә алган чараларны тормышка ашыруны финанслар белән тәэмин итү буенча муниципаль берәмлекнең чыгым йөкләмәләрен үтәүгә бюджет ассигнованиеләре булу;

бу Тәртипнең 10 нчы пункты нигезендә башка бюджетара трансфертлар бирү турында килешү төзү.

8. Башка бюджетара трансфертларны алу өчен муниципаль берәмлекләр Министрлыкка түбәндәге документларны тапшыра:

башка бюджетара трансфертлар бирү турында ирекле рәвештә язылган гариза;

муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы карарыннан вәкаләтле зат тарафыннан расланган һәм муниципаль берәмлек бюджетында Татарстан Республикасы бюджетыннан бирергә планлаштырыла торган башка бюджетара трансфертларны үз эченә алган чараларны тормышка ашыруны финанслар белән тәэмин итү буенча муниципаль берәмлекнең чыгым йөкләмәләрен үтәүгә бюджет ассигнованиеләре булуны раслый торган агымдагы финанс елына муниципаль берәмлек бюджеты (җыелма бюджет исемлеге) турында өземтә;

муниципаль берәмлекнең тормышка ашыру максатларында башка бюджетара трансфертлар бирү гамәлгә ашырыла торган чараларны күздә тота торган хокукый актының билгеләнгән тәртиптә расланган күчермәсен.

9. Башка бюджетара трансфертларны бирү Министрлык һәм муниципаль берәмлекнең җирле үзидарә органнары арасында Министрлык тарафыннан раслана торган форма буенча төзелгән башка бюджетара трансфертлар бирү турындагы килешү (алга таба – килешү) нигезендә гамәлгә ашырыла.

10. Килешүдә түбәндәгеләр карала:

башка бюджетара трансфертларның күләме, аларның максатчан билгеләнеше;

башка бюджетара трансфертларны күчерү тәртибе һәм вакытлары;

башка бюджетара трансфертлардан файдалану турында хисаплылык тапшыру вакытлары;

муниципаль берәмлектә коммуналь инфраструктура системасын модернизацияләү проектында каралган максатчан күрсәткечләргә муниципаль берәмлектә коммуналь инфраструктура системасын модернизацияләү проекты белән билгеләнгән вакытларда ирешмәү нәтиҗәләре;

башка бюджетара трансфертларны алучы тарафыннан килешүдә каралган йөкләмәләрнең үтәлешен тикшерүдә тотуны гамәлгә ашыру тәртибе;

муниципаль берәмлекләрнең формалаштыру һәм Торак-коммуналь хуҗалыкны реформалаштыруга булышлык күрсәтү фондына – дәүләт корпорациясенә кертү өчен кирәкле мәгълүматны, документларны бирү буенча йөкләмәләрне үтәмәгән яки тиешенчә үтәмәгән өчен җаваплылыгы;

якларның килешү шартларын бозган өчен җаваплылыгы.

11. Башка бюджетара трансфертлар муниципаль берәмлекләр бюджетлары акчасы белән операцияләрне исәпкә алу өчен Россия Федерациясе Үзәк банкы учреждениесендә ачылган Федераль казначылыкның Татарстан Республикасы буенча идарәсе счетына килешүдә билгеләнгән вакытларда билгеләнгән тәртиптә күчерелә.

12. Муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнары муниципаль берәмлекләр бюджетларының финанслар белән тәэмин итү чыганагы булып башка бюджетара трансфертлар торган чыгымнары турында һәм муниципаль берәмлектә коммуналь инфраструктура системасын модернизацияләү проектында каралган максатчан күрсәткечләргә ирешү турында Министрлыкка Торак-коммуналь хуҗалыкны үзгәртеп оештыруга булышлык күрсәтү фонды – дәүләт корпорациясе тарафыннан каралган форма, вакытлар һәм тәртип нигезендә хисаплар кертә.

13. Муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнары һәм аларның вазыйфаи затлары кертелә торган хисап мәгълүматларының дөрес булмавы һәм башка бюджетара трансфертлардан максатчан файдаланмау өчен законнар нигезендә җавап бирә.

14. Муниципаль берәмлек тарафыннан башка бюджетара трансфертлар бирү шартлары бозылган очракта, аңа карата Россия Федерациясе бюджет законнарында каралган мәҗбүр итү чаралары кулланыла.

15. Башка бюджетара трансфертлардан максатчан файдаланмау Татарстан Республикасы бюджетыннан алынган акча суммасын законнар белән билгеләнгән тәртиптә бәхәссез түләтүгә китерә.

16. Башка бюджетара трансфертларны максатчан файдалануны тикшерүдә тоту Министрлык тарафыннан законнар нигезендә гамәлгә ашырыла.